**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 28 март № 192

г. Казань

Түбән Кама һәм Тукай муниципаль районнары территориясендә «Алабуга-2. Нефть химиясе» индустриаль паркын төзү турында

Татарстан Республикасының Кама сәнәгать кластерын үстерү, нефть химиясе һәм нефть эшкәртү калдыкларын тирәнтен эшкәртү өлкәсендә производстволарны яңарту максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының, Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенең (алга таба – «Алабуга» СҖТ МИЗ» акционерлык җәмгыяте) Түбән Кама һәм Тукай муниципаль районнары территориясендә «Алабуга-2. Нефть химиясе» индустриаль паркын төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.
2. «Алабуга» СҖТ МИЗ» акционерлык җәмгыятен «Алабуга-2. Нефть химиясе» индустриаль паркы белән идарә итүче компания итеп билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, «Алабуга-2. Нефть химиясе» индустриаль паркының инфраструктура объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) төзекләндерү максатларында, «Алабуга» СҖТ МИЗ» акционерлык җәмгыяте идарә итүче компаниясенең 2017 елда субсидия бирү күләмнәре һәм чыганаклары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.
4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\192.docx